**Кукмара муниципаль районы**
**Байлангар авыл жирлеге Советы**

**КАРАР**

**«02» декабрь 2021 ел** **№ 39**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставы нигезендә Байлангар авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елның 14 декабренә 10 сәгать 00 минутка беренче этап, 2021 елның 14 декабренә 14 сәгать 00 минутка икенче этап «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктның беренче абзацында «500 сум» сүзләрен «800 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле унынчы абзацны өстәргә:

«-Байлангар авылының Гагарин урамына асфальт җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Байлар авыл җирлеге башлыгы: И. Ф. Кәримуллин